| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2026 ел Кукмара ш. № 39

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кумара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (2024 елның 27 декабрендәге 285 номерлы, 2025 елның 11 апрелендәге 302 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 1.2 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«и) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр,күпфатирлы йортта күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы урыннар милекчеләре белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яисә) ремонтлау эшләрен башкару буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән затлар, күпфатирлы йортта мондый урын милекчеләренә торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев